Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«08» октябрь, 2019 ел № 125

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы карарларын юкка чыгару турында

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 121нче тамгалы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында " карарын;

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 122 нче тамгалы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында» карарын юккачыгарырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урамы, 3;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе В.П. Оленин